| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«20» март 2023г. № 55

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 18 октябрендәге 213 номерлы «Муниципаль торак фондында урнашкан хезмәт торак урынына найм шартнамәсе буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 18 октябрендәге 213 номерлы «Муниципаль торак фондында урнашкан хезмәт торак урынына найм шартнамәсе буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Муниципаль торак фондында урнашкан хезмәт торак урынына найм шартнамәсе буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

А) түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда бирү очраклары һәм тәртибе каралмаган.»;

Б) 2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне таныклый торган башка документны күрсәтү юлы белән шәхесне таныклый торган документ;»;

в) 2.5.1 пунктының 9 пунктчасында «һ.б.» сүзләрен төшереп калдырырга;

Г) 2.10 пунктны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 52 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы һәм аларны күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» карары»;

Д) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә, гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары бар, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да.»;

Е) 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.»

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин